ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1637 6 декабря 2016 г.

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп коруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» карары нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп коруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Житәкче А.Г.Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы Түбән
Кама   муниципаль районы
Башкарма комитетының 2016 елның
6 декабрендәге 1637 номерлы карары
белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804  номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп коруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

1.1. 1.3.1. пунктының 2 абзацында «Актүбә урамы, 6 нчы йортта» сүзләрен «Мәктәп бульвары, 2а йорт» сүзләрен алмаштырырга.

1.2. 1.3.1. пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты: 12 сәгать 00 минуттан 13 сәгать 00 минутка кадәр».

1.3.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10 нчы абзац өстәргә. «Документлар 2 нче катта, «төзелеш бүлеге» кабинетында кабул ителә».

1.3. 1.3.3. пунктының 1 пунктчасында, 1.3.4. пунктында «Башкарма комитет урыннарында» сүзләрен «Идарә урыннарында» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза алынган көннән ун көн эчендә».

1.5. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза алган көннән соң ун көн эчендә, РФ ГрКның 51 статьясындагы 11.1 өлешендә каралган очрактан тыш.».

1.6. 2.5 Пункт. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.5.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору максатыннан тәкъдим ителә:

1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, әгәр күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында юк икән;

1.1) Россия Федерациясе бюджет законнарында, дәүләт хакимияте органында (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фонд белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән очракларда, бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшыру турында килешү - күрсәтелгән килешү, әлеге килешү төзелгән хокук иясенең җир кишәрлегенә җиргә хокукны билгеләүче документлар булганда;

2) төзелешкә рөхсәт алу өчен гариза биргән көнгә кадәр өч елдан да иртәрәк бирелмәгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы, яисә линияле объектны

төзүгә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты реквизитлары (мөрәҗәгать итүче теләге белән тапшырыла);

3) проект документларындагы материаллар:

а) аңлатма язуы;

б) җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә, капиталь төзелеш объектының, подъездларның һәм аңа керү урыннарының урнашу урынын, гавами сервитутларның, археологик мирас объектларының эшчәнлек зоналары чикләрен күрсәтеп башкарылган җир кишәрлеген планлаштыруны оештыру схемасы;

в) линияле объектларга кагылышлы территорияне планлаштыру документлары составында расланган линияле объектының кызыл линияләр чикләрендә урнашуын раслаучы җир кишәрлеген планлаштыруны оештыру схемасы;

г) архитектура чишелеше;

д) инженерлык җиһазлары турында белешмәләр, проектлана торган капиталь төзелеш объектының инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) урыннарын билгеләү белән инженер-техник тәэмин итү челтәрләренең җыелма планы;

е) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты;

ж) капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен җимерү яки сүтү эшләрен оештыру проекты;

з) әлеге объектларны төзегәндә, үзгәртеп корганда, әлеге объектларның проект документларына экспертиза РФ ГрКның 49 статьясы нигезендә үткәрелмәгән булса, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм башка социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына инвалидларның керә алуын тәэмин итү чаралары исемлеге;

4) әгәр мондый проект документларына РФ ГрКның 49 статьясы нигезендә экспертиза үткәрергә булса, капиталь төзелеш объектының проект документларына (РФ ГрКның 48 статьясындагы 12.1 өлешендә каралган очракта, төзелешнең аерым этапларына карата) уңай экспертиза бәяләмәсе, РФ ГрКның 49 статьясындагы 3.4 өлешендә каралган очракларда, проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе. РФ ГрКның 49 статьясындагы 6 өлешендә каралган очракларда, проект документларына дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе;

4.1) модификацияләнгән проект документларыннан файдаланганда, РФ ГрКның 49 статьясындагы 3.5 өлешендә каралган бәяләмә;

5) рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт (әгәр төзүчегә мондый рөхсәт РФ ГрКның 40 статьясы нигезендә бирелгән булса) – мөрәҗәгать итүче теләге буенча тапшырыла;

6) мондый объектны згәртеп корган очракта, капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы, 6.2 пунктта күрсәтелгән күпфатирлы йортны үзгәртеп кору очракларыннан тыш;

6.1) дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фонд белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы булган дәүләт (муниципаль) заказчысы тарафыннан дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе хокук иясе булган дәүләт (муниципаль) милкенең капиталь төзелеш объектында, аңа карата әлеге орган гамәлгә куючы яисә мөлкәт милекчесе хокуклары функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) бюджет яисә автоном учреждениесендә үзгәртеп кору үткәргән очракта - шул исәптән үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда күрсәтелгән объектка китерелгән зыянны каплау шартларын һәм тәртибен билгели торган мондый үзгәртеп кору уздыру турындагы килешү;

6.2) күпфатирлы йортны үзгәртеп корганда, торак законнары нигезендә кабул ителгән күпфатирлы йортта урыннар һәм машина-урыннары милекчеләренең гомуми җыелышы карары, яки, әгәр мондый үзгәртеп кору нәтиҗәсендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт күләме киметелсә, күпфатирлы йортта урыннар һәм машина-урыннарының барлык милекчеләренең ризалыгы;

7) проект документларына дәүләти булмаган экспертиза бәяләмәсе бирелгән очракта, проект документларына дәүләти булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсен биргән юридик затны аккредитацияләү турындагы таныклык күчермәсе;

8) мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкарганда, мондый объектның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының конструктив һәм башка характеристикаларына кагыла икән, мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында каралган документлар.».

2. Индивидуаль торак төзелеше объектын төзү, үзгәртеп кору максатларында, төзүче, түбәндәге документларны кушып, төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза җибәрә:

1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, әгәр күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында юк икән;

2)төзелешкә рөхсәт алу өчен гариза биргән көнгә кадәр өч елдан да иртәрәк бирелмәгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы (гариза бирүче теләге буенча тапшырыла);

3) индивидуаль торак төзелеше объектын урнаштыру урынын күрсәтеп, җир кишәрлеген планлаштыруны оештыру схемасы;

4) әгәр индивидуаль торак төзелеше объектын төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылса, РФ ГрКның 51 статьясындагы 10.2 өлешендә каралган очрактан тыш, индивидуаль торак төзелеше объектының тышкы күренешен тасвирлау. Индивидуаль торак төзелеше объектының тышкы кыяфәтен тасвирлау текст формасында аның тасвирламасын һәм график тасвирламасын үз эченә ала. Индивидуаль торак төзелеше объектының тышкы кыяфәтен текст формасында тасвирлау индивидуаль торак төзелеше объектының параметрларына күрсәтмәне, аның тышкы күренешен төс ягыннан хәл итүне, мондый объектның тышкы күренешен билгели торган файдаланырга планлаштырыла торган төзелеш материалларын, шулай ук мондый объектның башка характеристикаларын

тасвирлауны, капиталь төзелеш объектының архитектура чишелешенә таләпләр буларак шәһәр төзелеше Регламенты тарафыннан куелган таләпләрне үз эченә ала. График тасвирлау, аның фасадлары һәм объект конфигурациясен кертеп, индивидуаль торак объектының тышкы күренешен тасвирлау булып тора.

1.7. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

Регламентның 2.5 пунктындагы 1 өлешенең 1, 2 һәм 5 пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), әгәр мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырмаган булса.

Регламентның 2.5 пунктындагы 2 өлешенең 1, 2 пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), әгәр мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырмаган булса.».

1.8. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нигезләр каралмаган»

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) тиешле булмаган зат тарафыннан гариза бирү;

2) тиешле булмаган органга документлар тапшыру;

3) Регламентның 2.5 пунктында каралган мәҗбүри документлар булмаганда;

4) тапшырылган документларның тәкъдим ителгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын төзүгә рөхсәт алу өчен бирелгән көнгә билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата таләпләргә туры килмәве;

5) линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, тапшырылган документларның территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә туры килмәве;

6) тапшырылган документларның җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төренә һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләргә туры килмәве;

7) тапшырылган документларның рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан читләшүгә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.».

1.9. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә гариза кергән көнне башкарыла».

1.10. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме» баганасының 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган урыннарга, мөрәҗәгать итүчеләрне көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларга социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның

инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр».

1.11. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда гамәлгә ашырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә күчеп йөрү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.».

1.12. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.15. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:

бина җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашкан;

кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләр булу;

муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат мәгълүмати такталарда, «Интернет» челтәрендә, Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында булу;

законда каралган инвалидлар өчен уңайлы шартлар булу.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:

гариза бирүчеләргә документлар кабул итү һәм бирү чиратлары;

муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;

муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ), КФҮнең читтән торып эш урыннарында муниципаль хезмәт күрсәткәндә, консультация, документларны кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара».

1.13. 3.2.1 пунктында «Бүлек» сүзен «Идарә» сүзенә алмаштырырга.

1.14. 3.3.2. пунктының 3, 5, 6, 9 нчы абзацларын төшереп калдырырга.

1.15. 3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Белгеч Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында соратуны ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза кергән көннән алып өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт һәм муниципаль органнарга җибәрелгән соратулар.».

1.16. 3.4.2 пунктының 2 абзацында «биш көн» сүзләрен «өч эш көне» сүзләренә алмаштырырга.

1.17. Регламентның 3.5.1 пунктындагы 2 абзацны төшереп калдырырга.

1.18. 3.5.1 пунктының 7 абзацында «Җитәкче урынбасарына» сүзләрен «Җитәкче» сүзләренә алмаштырырга.

1.19. Регламентның 3.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәргә:

«3.5.1. Рөхсәт бирү турындагы мәсьәлә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан төзелгән комиссия карап тикшерүенә чыгарылырга мөмкин.».

1.20. 3.5.2 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (аның вәкаләтле заты) рөхсәт яисә нигезле рәвештә баш тартуга кул куя һәм теркәү өчен Идарәгә җибәрә».

1.21. 3.6.1 пунктының 2 абзацында «рөхсәт бирү турында (рөхсәт бирүдән баш тарту турында) карар» сүзләрен «рөхсәт (рөхсәт бирүдән баш тарту турында карарлар)» сүзләренә алмаштырырга.

1.22. 3.7.3 пунктында «Бүлек» сүзен «Идарә» сүзенә алмаштырырга.

1.23. 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларның эзлеклелегенә агымдагы контрольне Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (төзелеш буенча) гамәлгә ашырыла.».

1.24. 5.1. пунктында «яисә муниципаль берәмлек Советына» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.25. 5.7 пунктында «(муниципаль район башлыгы)» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.26. Административ регламентка 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

2 нче кушымта

# Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы

